Татарстан Республикасы
Нурлат шәһәре "1нче урта гомуми белем мәктәбе"
гомуми белем автоном муниципаль учреждениесе

Каралды:
Методик берләшмә җитәкчесе:
____ Нәбиуллина Ф.М.
Беркетмә №1,
"17" 08 2015ел.

Килешенде:
Уку-укыту эшләре
буенча директор
урынбасары:
Сатдарова Л.Ә.
"20" 08 2015 ел.

Раслыйм:
Директор

Головенькина А.Н.
Боерык №134
"21"08.2015ел

8 нче сыйныф (рус төркеме) өчен

әдәбияттан эш программасы

Төзүче: Мугайнетдинова Рузалия Тәлгать кызы,

1 нче категорияле татар теле һәм

әдәбияты укытучысы

2015-2016 нчы уку елы

1.Аңлатма язуы

Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы.
1. - 6 статья – белем алу теле (телләре)
2. -10 статья –уку-укыту программалары
3. - 32 статья – мәгариф учреждениесенең вәкаләтләре һәм җаваплылыгы.
3. ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010 нчы ел.
4. . «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 8нче с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Г.Г.Мулласалихова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт, 2015ел
4. Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең “1нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2015-2016нчы уку елына укыту планы.

2.Укыту предметына гомуми аңлатма

Татар әдәбиятыннан 5 нче, 6 нчы, 7 нче, 8 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән программа дәүләт стандартларының федераль компонентына, гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнгән Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова тарафыннан язылган дәреслекләрдән (1 нче, 2 нче кисәк) укытуны күздә тота. Программа стандартның эчтәлеген җентекләп ачып бирә, стандарт таләп иткән күләмдә рус телле балаларга татар әдәбиятын укытуның гомуми юнәлешләрен билгели, предмет чаралары белән укучыларны тәрбияләү юлларын, аларның әдәби үсеш дәрәҗәсен билгели.

Күпмилләтле аудиториядә татар әдәбиятын укыту өчен төзелгән программа бербөтен документ булып тора, ул биш өлешне иңли: аңлатма язуы; укыту курсының эчтәлеге, укыту-тематик планы; укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр; курсның укыту-методик тәэмин ителеше өчен әдәбият исемлеге.

Әдәбият һәр яктан үскән, рухи яктан бай, әхлакый идеаллары һәм эстетик таләпләре булган камил шәхес тәрбияләүдә әһәмиятле урын алып тора. Урта белем бирү системасындагы татар әдәбияты курсы сәнгатьне тормыш белән бәйләп өйрәнүне, эчтәлек белән форма берлеге, тарихилык, традиция һәм новаторлык, тарихи-культурологик мәгълүматларны аңлау, әхлакый-эстетик күзаллау булдыру, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча төшенчәләрне үзләштерү, әдәби әсәрне бәяләү күнекмәләрен формалаштыру, әдәби телнең сәнгатьлелек чаралары белән танышуны үз эченә ала.

Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә (фундаментальное ядрога), универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту

һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып-белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа. Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның **иҗтимагый** үсешенә (халыкның рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); **шәхси** үсешенә (үзлегеннән белем алырга, иҗади сәләте үскән, компетентлы, үзаңы үскән, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерүгә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди карашта торган, тормыш авырлыкларына каршы торырлык шәхес тәрбияләү); **танып белү** эшчәнлеген үстерүгә (фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып-белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле укучы тәрбияләү); **коммуникатив** үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңларга, диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, рус телен, чит телне камил белүенә) басым ясалды. Шул ук гамәлләрне тормышка ашыру барышында, яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алынды.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре дүрт блокка бүлеп карала. Алар арасында **шәхси** УУГ − тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. Р**егулятив** уку гамәлләре шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала. **Танып белү** гамәлен алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомумуку гамәлләренә игътибар ителә. **Коммуникатив** УУГ кешеләр язмышына битараф булмауны, кешеләргә ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала.

Федераль дәүләт стандартларына таянып, татар әдәбиятын өйрәнүнең **максаты** – туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

− Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

− татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

− татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

− татар әдипләре, мәдәният әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, аңларга, башка халык сүз сәнгатен үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

− татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен, түбәндәге принциплар истә тотылырга тиеш. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар әдәбиятының асылын төшендерү укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүен, иҗади эшләү күнекмәләре булуын таләп итә. Мәктәп баласына сүз сәнгатенең серләрен ачуда **эстетик принцип** (укытучының матурлыкны күрә

алуы һәм башкаларны да күрергә өйрәтә алуы), **эзлеклелек** (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), **әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү** (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләре, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), күләме ягыннан кечкенә булган әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт булдыру, ягъни **психологик принцип** (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, әдәби әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып эш итү) ярдәмгә килә. Аерым игътибар **коммуникативлык принцибына** бирелә. Бу принципның өстен чыгуы рус телендә сөйләшүче укучыларның әдәби әсәр аша татар теленең серләренә тирәнрәк төшенүләре, матур әдәбият әсәрен сорауларга нигезләнеп сөйли алуы, үз фикерләрен ачык әйтә алуы, әдәби әсәрнең аралашу чарасына әверелүе белән дә бәйле. Укучыларның әдәби әсәрне кабул итү һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, **дифференциацияләү** (аерым төркемнәргә аерып, бүлеп эшләү) һәм **интеграцияләү** (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә алынган теоретик белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) дә үзәккә алына.

3.Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Сәгать саны: барлыгы 70 сәгать, атнага 2сәгать
Әсәрләрне уку һәм өйрәнү – 58 сәгать
Бәйләнешле сөйләм үстерү – 7 сәгать
Дәрестән тыш уку – 4 сәгать
Еллык кабатлау – 1 сәгать

Планлаштыру нигезе:
Программа : ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011нче ел.
Дәреслек . «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 8нче с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Г.Г.Мулласалихова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт, 2015ел

4.Эшчәнлек төрләре һәм күнекмәләр

1. Әкиятләр, аларның төрләрен, геройларның төп сыйфатларын аера белү. Язучылар язган әкиятләрнең үзенчәлекләрен белү.
2. Табышмаклар, шарадалар һәм укучыларның тапкырлыгын, зирәклеген билгеләүдә аларның ролен аңлау.
3. Хикәя, фантастик хикәя, повесть, нәсерне аера белү.
4. Автобиографик повестьнең, шигырь һәм поэманың, мәсәл жанрының үзенчәлекләрен белү.
5. Өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү. Укылган текст буенча әңгәмәдә катнаша алу.
6.Өйрәнелгән язучыларның тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру.
7. Әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү. Геройларга характеристика бирү. Әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау. Әдәби әсәрнең сюжетын тотып ала белү.Әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү.
8. Шигырьне яттан белү яки прозадан өзекне яттан сөйләү.

9. Балалар өчен басылган вакытлы матбугат материалларын уку һәм файдалана алу.
10. Аңлап, йөгерек, сәнгатьле уку, уку тизлеге 1 минутка 80-85 сүздән ким булмаска тиеш. Аңлап һәм эчтән шома уку күнекмәләренә ия булу. Дөрес, тиешле тон һәм интонацияне сайлап, сәнгатьле уку ярдәмедә текстның эчтәлеген төшендерә алу

5.Укыту предметының төп эчтәлеге

Эчтәлек	Сәгать саны
Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана..	5
Без тарихта эзлебез	8
Онытылмас еллар	12
Әтинең зур бүреге иртә киелде	7
Ана – изге, Ана – бөек, Аңа – дан!	15
Көлсәң — көл, еласаң — ела	7
Дaһи гомере – халкы хәтерендә!	8
Табигатьнең дә җаны, рухы бар	8
Барысы:	70

6. Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр һәм көтелгән нәтиҗәләр

- әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;
- авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, әсәрне өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
- әдәби-теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;
- татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
- авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
- 10—12 татар, рус, чит ил язучы, шагыйрьләренең исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
- 4 – 5 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;
- Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы һ.б.), балалар матбугаты турында белү;
- төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;
- 6 мәкаль, 6 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;
- төрле авторларның 3 – 4 шигырен яттан сөйли белү;
- сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;
- төрле темаларга проект эше яклау;
- әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

7. Тематик планлаштыру

№	**Темалар**	**Әсәрләрне өйрәнү**	
		Төп программада әсәрләрне өйрәнү өчен каралган	**Эш программасындагы сәгать саны**

		сәгать саны	
1	Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана..	5	5
2	Без тарихта эзлебез	8	8
3	Онытылмас еллар	12	12
4	Әтинең зур бүреге иртә киелде	7	7
5	Ана – изге, Ана – бөек, Аңа – дан!	15	15
6	Көлсәң — көл, еласаң — ела	7	7
7	Дәһи гомере – халкы хәтерендә!	8	8
8	Табигатьнең дә җаны, рухы бар	8	8
9	Барысы:	70	70

8. Календарь – тематик план

№	Дәрес темасы	Сәг. саны	Эсчтәлек (Төп төшенчәләр)	Милли-төбәк компоненты	Үтәлү вакыты	
					план	факт
	Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана..	**5**				
1	Ачыла тарихның пәрдәсе.	1	Халык авыз иҗаты, риваять жанрына гомуми күзаллау булдыру. “Сихерче кыз” риваятен уку.		2.09	
2	Сезгә ялган, миңа чын.	1	“Гали туган”, “Моргана” риваятьләрен уку.		5.09	
3	Дәрес-проект “Халыкныкы халыкта саклана” .	1	Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Риваять темасын гомумиләш-тереп кабат-лау.		9.09	
4	Сезгә ялган, миңа чын.	1	Легенда жанрына гомуми күзаллау булдыру.		12.09	
5	Моңы барның йөрәгеннән Һәрвакыт җылы чыгар.	1	Милли уен кораллары белән танышу.	Нурлат сәнгать мәктәбе турында сөйләшү	16.09	
	Без тарихта эзлебез	**8**				
6	Тарих – тормыш остазы.	1	Ибн Фадлан һәм аның 921 – 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе белән танышу.		19.09	
7	Гыйлемсез кеше – канатсыз кош.	1	Фатих Кәрими иҗаты. “Ауропа сәяхәтнамәсе”		23.09	

			белән танышу.			
8	Энҗе табучы әдип.	1	Миргазыян Юныс иҗаты,. “Су”хикәясен уку.		26.09	
9	Җиктереп пар ат, Казанга.	1	Габдулла Тукай иҗаты. “Пар ат” шигырен өйрәнү	Г Кариев турында мәгълумат бирү	30.09	
10	Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур.	1	“Пар ат” шигыренә анализ.		3.10	
11	Милли мәдәниятебезне үстерүдә Бакый Урманче иҗаты.	1	Бакый Урманче иҗаты белән танышу.		7.10	
12	Нажар Нәҗми - Тукай шәкерте.	1	Нажар Нәҗминең иҗаты, “Агыйделдә ак пароход” әсәре.		10.10	
13	Үзенең үткәнен онытқан халыкның киләчәге юк.	1	Укылган әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне кабатлау.	Нурлат язучыларының шигырьләрен уку	14.10	
	Онытылмас еллар	**12**				
14	Билгесез биеклектә.	1	Рәссам Виктор Куделькинның иҗаты. Гариф Ахуновның “Замандашлар портретын” уку.		17.10	
15	Тырышса да дошман, шагыйрьләрне аералмый җырдан, халыктан.	1	Роберт Әхмәтҗановның “Озатып вокзаллар каршында” һәм татар халык җыры “Герман көе”белән танышу.		21.10	
16	Патриот-шагыйрь.	1	Фатих Кәрим иҗаты.“Ант” шигырен өйрәнү.		24.10	
17	Үлем турында уйлама, илең турында уйла.	1	Фатих Кәримнең “Кыңгыраулы яшел гарун” поэмасын уку.		28.10	
18	Үлем турында уйлама, илең турында уйла.	1	Фатих Кәримнең “Кыңгыраулы яшел гарун” поэмасын уку (дәвамы)		31.10	
19	Исемең калды	1	Туфан Миңнуллин иҗаты.		11.11	

	моңлы бер җыр булып...					
20	Исемең калды моңлы бер җыр булып...	1	Туфан Миңнуллин .Моңлы бер җыр” драмасы.		14.11	
21	Һәйкәлләргә килик, гөлләр куйыйк Һәйкәлләрне тыңлыйк тын гына.	1	Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар		18.11	
22	Каз канаты каурый-каурый, Хатлар язарга ярый.	1	Хат үрнәкләре белән танышу, Бөек Ватан сугышы.батырларының фронт хатларын уку.		21.11	
23	Син күрсәткән батырлыкны, солдат, Халкым сөйли мактап бүген дә..	1	Мостай Кәрим иҗаты. “Билгесез солдат” шигыре.	Алмаз Фәхретдинов турында сөйләшү	25.11	
24	Дөньяда тик бары яхшылык кына үлми.	1	Чыңгыз Айтматов иҗаты. “Анам кыры” әсәре.		28.11	
25	Без азатлык алып биргән көннәр, Хәтерләми икән кем генә!	1	“Онытылмас еллар” бүлегендә өйрәнгән материалны кабатлау.		2.12	
	Әтинең зур бүреге иртә киелде	7				
26	Җиңүне якынайткан җыр.	1	Клара Булатова иҗаты. «Башым иям» шигыре белән танышу.	Х Туфан турында сөйләшү	5.12	
27	Тынычыкның туган көнен Бәйрәм итә бүген илем...	1	Н.Әхмәдиев иҗаты. «Җиңү көне» шигыре, “Минем туган көнем” хикәясе		9.12	
28	Тынычыкның туган көнен Бәйрәм итә бүген илем...	1			12.12	
29	Шәфкатьлелек бизи кешене!	1	Ф.Сафинның иҗаты.“Тулганай” әсәре.		16.12	
30	Контроль эш	1			19.12	
31	Таң булып нур сибә Ватаным.	1	Рәзил Вәлиев иҗаты.«Ватаным» шигыре.		23.12	
32	Җиңү көне җиңел	1	“Вакыт сынавы аша..”	Нурлат	26.12	

	бирелмәде.		проект ларны яклау.	районы геройлары турында сөйләшү		
	Ана – изге, Ана – бөек, Аңа – дан!	**15**				
33	Бәхет эзләгәндә.	1	Шәриф Камал иҗаты.“Буранда” хикәясен уку.		13.01	
34	Исән чакта белү кирәк икән, Әти-әниләрнең кадерен.	1	Шәриф Камалның “Буранда” хикәясен өйрәнү.		16.01	
35	Тайгак кичүләрне кичкән шагыйрь.	1	Ибраһим Салахов иҗаты. Колыма хикәяләре циклыннан “Ана тавышы”		20.01	
36	Тетрәндергеч еллар авазы.	1	Ибраһим Салаховның Колыма хикәяләре циклыннан “ Ана тавышы”.		23.01	
37	Ана күңеле – балада.	1	Сибгат Хәким иҗаты, “Әнкәй” шигыре.	Г.Сәгыйро в әсәрләре	27.01	
38	Җырларымда телим.	1	Сибгат Хәкимнең “Җырларымда телим” шигыре.		30.01	
39	Әнкәйләрдән күргән игелек.	1	Туфан Миңнуллин иҗаты, “Әнкәй” шигыре.		3.02	
40	Туган җирләр әнкәй белән.	1	Марсель Галиев иҗаты.“Су буеннан әнкәй кайтып килә шигыре”.		6.02	
41	Кабатланмас әкият.	1	Марсель Галиевның “Кабатланмас әкият” шигыре.	И.Диндаро в әсәрләре	10.02	
42	Ата-анага бурычны бары тик кеше булып кына түләп була.	1	Шәриф Хөсәенов иҗаты. “Әни килде” драмасы		13.02	
43	Ата-анага бурычны бары тик кеше булып кына түләп була	1	“Әни килде” драмасыннан “Әниемнең ак күлмәге” өзеген уку.		17.02	
44	Әти-әни кадере	1	Гаилә турында сөйләшү		20.02	
45	Ана куллары.	1	Фоат Садриев иҗаты. “Таң җиле”әсәре.		24.02	
46	Г.Кариев –күренекле якташыбыз	1	Г.Кариев музее	Г.Кариев музее турында	27.02	
47	Кая барсам – әнкәй күңелдә.	1	Ана – бөек исем! Нәрсә җитә ана булуга... бүлеген гомумиләштереп кабатлау, бәйләнешле сөйләм үстерү.		2.03	
	Көлсәң — көл, еласаң — ела	**7**				

48	Күңелсездән көлке чыкмас.	1	Сатирик журналлар, Галиәсгар Камал иҗаты	“Дуслык” газетасы материаллары	5.03	
49	Хәйләсез дөнья файдасыз.	1	Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе.		9.03	
50	Хәйләсез дөнья файдасыз.	1	Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясен укуны дәвам итү.		12.03	
51	Һәр заманның үз герое була.	1	Гамил Афзал иҗаты. “Юл газабы” хикәясе.		16.03	
52	Сүз күңелдә очкын булып көйри.	1	Гамил Афзалның “Тәвәккәл әби” шигыре.		19.03	
53	Озын сүзнең кыскасы.	1	Зәки Нури иҗаты, пародия, эпиграммалар		2.04	
54.	Көлке дисәң дә көлке!	1	“Көлсәң — көл, еласаң — ела” бүлеген гомумиләштереп кабатлау.		6.04	
	Дәһи гомере – халкы хәтерендә!	**8**				
55	Көйләрдән тезмәләр тездем.	1	Ринат Харис иҗаты.“Гармунчы” поэмасы.	Т.Бадыйгин турында мәгълумат бирү	9.04	
56	Минем тирәмдә Кояш үзе әйләнә.	1	Ринат Харисның “Ике гөл” шигыре.		13.04	
57	Шигырем- ачык!	1	Зөлфәт иҗаты. “Шигырем-ачык”шигыре.		16.04	
58	Ерактагы моңлы бер көй булып.	1	Зөлфәтнең “Шундый чагы әле җанымның” шигыре.		20.04	
59	Ил җыр белән яши.	1	Галия Кайбицкая иҗаты.	Нурлаттан чыккан артистлар турында сөйләшү	23.04	
60	Сәхнә хуҗасы.	1	Рабит Батулла иҗаты.		27.04	
61	Сәхнә хуҗасы.	1	Рабит Батулла иҗаты. Бию *(«Бию җене кагылган егет» кыйссасыннан*		30.04	
62	Иҗат – ул яшәү рәвеше.	1	Иҗат процессы бүлеген гомумиләштереп кабатлау.		4.05	
	Табигатьнең дә җаны, рухы бар	**8**				
63	Батыр Җайдак	1	Айдар Хәлим иҗаты,.“Өч аяклы ат” повесте		7.05	
64	Фронттан кайткан ат.	1	Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” повесте.		11.05	
65	Авырлык җебе	1	Айдар Хәлимнең “Өч		14.05	

	өзелде.		аяклы ат” повесте.			
66	Арадаш аттестация эше.	1	Арадаш аттестация эше.		18.05	
67	Табигатьнең чәчәк аткан чагы.	1	Гәрәфи Хәсәнов .“Беренче күк күкрәү” хикәясе.		21.05	
68	Ямьле сабантуйлары.	1	Камил Каримов ижаты, “Тимергали бабай хикәяте”		25.05	
69	“Ялкын” журналына сәяхәт.	1	“Ялкын” журналы. Табигатьнең дә жаны, рухы бар бүлеген гомумиләштереп кабатлау.	“Дуслык “газетасы турында сөйләшү	28.05	
70	Күңелемә уелып калган әсәрләр Әдәбият дигән олы диңгез	1	Ел буена үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау		30.05	

9.Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү

- Укыту процессы түбәндәге матди-техник һәм мәгълүмати ресурслар белән тәэмин ителгән:
- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы;
- татар телен өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- компьютер классы, татар теле кабинетында интерактив такта;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары, компьютер программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- белемнәрне интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары.

КУРСНЫҢ УКЫТУ-МЕТОДИК ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕ ӨЧЕН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Укытучы өчен:

1. Аминева В.Р. Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй пол. XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в.) / В.Р.Аминева. – Казань: Казан. ун-т, 2010. – 474 с.

2. Амирханов Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки / Р.У.Амирханов. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2005. – 152 с.

3. Арсланов М.Г. Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар / М.Г.Арсланов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 бит: фот.б-н.

4. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

5. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда / төз. Р.Н.Даутов, Р.Н.Рахмани. – Казан: Татар.кит.н.шр., 2009. – Т.I. – 751 б.; Т.II. – 735 б.

6. Әминев А.Г., Әдһәмова Г.М. Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы / А.Г.Әминев. − Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

7. Әминев А.Г., Сайкин Ш.Р. V – VII классларда әдәбият укыту методикасы /Абдулла Әминев, Шәриф Сайкин. − Казан: Татар. кит. нәшр., 1965

8. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: Шигырьләр һәм поэмалар. [Төз. һәм кереш сүз авт.Р.Х.Хәйбрахманов]. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшр. (ТаРИХ), 2005. – 416 б.

9. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү / Фоат Галимуллин. − Казан: 1988.

10. Гилязов А.М. Три аршина земли; В пятницу вечером / Аяз Гилязов. – Казань: Магариф, 2008. – 295 с.

11. Еники Ә. Сайланма әсәрләр / [Төз. һәм кереш сүзавт. Ә.Р.Мотыйгуллина]. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшр. (ТаРИХ), 2002. – 416 б.

12. Есин А.Б. Принципы и приемы анализа литературного произведения: Учебное пособие. – 8-е изд. /А.Б.Есин. – М.: Флинта: Наука, 2007. – 248 с.

13. Җамалетдинов Л. Әкиятләр // Фольклор жанрларын анализлау. – Казан, 1986. – Б.89-91.

Укучы өчен:

1. «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 5 нче с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Л.Х.Хисмәтова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт», 2014 ел.

2. «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 6 нчы с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Э.Х.Гыйзәтуллина. – Казан: «Мәгариф-Вакыт», 2014 ел.

3. «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 7 нче с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Г.Г.Мулласалихова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт

4. «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 8нче с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Г.Г.Мулласалихова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт, 2015ел